ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 28 гыйнвары** **Чистай шәһәре** **№ 53**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитеты карарларының
үз көчен югалтуын тану турында

Чистай шәһәр прокуратурасының муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру функцияләрен үтәүнең административ регламентына 2022 елның 25 гыйнварындагы 02-08-02-2022 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 8 февралендәге 59 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча административ регламентын;
- Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалыгы, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге тарафыннан Муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру функцияләрен башкаруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 23 гыйнварындагы 27 номерлы карарын.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов